

Мордовия автономиясенен 95 еллыгы 10 январьда билгеләп vтеләчәк. Бу конне 1930 елда Ботенроссия Үзәк Башкарма Комитеты Президиумы Мордовия округын Мордовия Автономияле олкәсенә vзгәртеп кору турында Карар кабул итә, ана РСФСР составындагы автономияле олкәләр очен законнарда билгеләнгән хокуклар бирелә. Бәйрәмне каршы алырга жыенганда Россия Федерациясенен һәм Мордовия Республикасынын атказанган табибы, Дәvләт Жыенынын социаль сәясәт комитетын житәкләгән Рафаиль Зәки улы Аширов белән әнгәмә кордык. Без әлеге шәхес белән кvптән тыныш, аны Мордовиядә һәм чит олкәләрдә беләләр: Зәки улы Рафаиль Ашировнын биографиясе олы китаплар язарга житә.      Үз язмышын ул Мордовия белән тыгыз бәйли. Медицина фәннәре докторы, профессор Рафаиль Ашировнын бvләкләре арасында Мордовия Республикасынын II һәм III дәрәжә Дан орденнары, Халыклар Дуслыгы ордены һәм кvп санлы һонәри бvләкләре бар. Ватан медицинасы vсешенә керткән зур олеше очен «Коткару һәм мәрхәмәт» Гиппократ ордены аерым урын алып тора. Ул оч чакырылыш Госсобрание депутаты иде, шул исәптән вице-спикер вазифасында да vз һонәри тәжрибәсен гражданнарнын иминлеге бәйле булган мәсьәләләрне хәл итv очен кулланды. Аралашу вакытында Рафаиль Зәки улы Аширов рәхәтләнеп vзебезчә, татарча Мордовиядәге эше турында сойләде. Ул:

- 2025 ел Мордовия Республикасы очен истәлекле ел булырга вәгъдә итә, чонки республикага берьюлы берничә моһим юбилейны билгеләп vтәргә туры киләчәк; алар тобәкнен бай тарихын ассызыклап кына калмыйча, киләчәктә мәдәни һәм социаль vсеш очен момкинлекләр дә тудыра.

Мордовия автономиясе оешуга 2025 елнын 10 январында 95 ел тулуны регионыбызда кин колач белән билгеләп vтәчәкбез. Бу вакыйга республика тарихында моһим вакыйга булачак һәм аны әзерләvгә тобәк файдасына эшләvчеләрнен барысын да жәлеп итv планлаштырыла. Мордовия Главасы Артём Здунов Дәvләт Жыелышына юлламасында чараларны югары дәрәжәдә уздыру кирәклеген ассызыклады. Бәйрәм кысаларында кvргәзмәләр, конференцияләр һәм мәдәни чаралар оештырылыр дип котелә; алар vткәннәрне искә тошереп кенә калмыйча, киләчәккә дә кvз салырга момкинлек бирәчәк. Ә бит Мордовия тарихы Россия дәvләте язмышы белән тыгыз бәйләнгән. Кvп гасырлар

дәвамында без биредә яшәүче халыклар белән бергә Ватаныбызны төзедек, сакладык һәм ныгыттык. Мордовия округын автономияле өлкәгә үзгәртеп кору республиканың икътисадый һәм социаль өлкәсен алга таба формалаштыруга нигез салды, мордва халкының милли телләрен, үзенчәлекле мәдәниятен һәм гореф-гадәтләрен үстерүгә көчле этәргеч булды.
Бүген Мордовия - җитештерү-техник, мәдәни, фәнни һәм кадрлар потенциалы зур булган перспективалы, яшәү өчен унайлы территория. Регионның барлык уңышлары һәм казанышлары - республика халкы күп буыннарының көндәлек хезмәте нәтиҗәсе.
Ә бит Рафаиль Зәки улы Аширов Мордовия автономиясенең 95 еллыгын үзенең профессиональ, иҗтимагый һәм башка төр уңышлары белән каршы ала. Аның тормышы һәм гамәлләре җәмәгатьчелек игътибары үзәгендә.
Рафаиль Зәки улы Аширов ике дистә елга якын Мордовия Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгын җитәкли. Кырык елдан артык гомерен медицина тармагына багышлый һәм күп нәрсә эшләргә өлгерә. Рафаиль Аширов 90 нчы еллар башындагы икътисадны реформалаштыру чорында шактый зыян күргән медицина учреждениеләре структурасын сак-лап калу һәм камилләштерү өстендә эшләде. Министр вазифасында ул тузган фельдшер-акушерлык пунктларын ремонтлау, районнарда яңа хастаханәләр һәм поликлиникалар төзү, аларны профессиональ кадрлар һәм заманча җиһазлар белән тәэмин итү мәсьәләләрен хәл итте. Республика клиник хастаханәсен аның да казанышы дип атарга хаклы, чөнки аның вакытында барлык оештыру моментлары хәл ителгән, проект эшләнгән һәм расланган, нигез салынган, төзелеш алып барылган, җиһазлар сатып алынган. Кан тамырлары, гемодиализ, радиология һәм перинаталь үзәкләр булдыруга күп көч биргән. Башкача әйткәндә, Аширов Рафаиль Зәки улы медицина төзелеше объектларында да, диагностика һәм дәвалауның иң алдынгы технологияләрен үзләштерү процессында үзен бик яхшы оештыручы итеп күрсәтте. Аңа белеме, фәнни якын килү, энергияле характер, куелган максатка ирешергә омтылу ярдәм иткән. Шунысын әйтеп китү дә урынлы булыр: 1979 елда Рафаиль Зәки улы Респуб-лика клиник хастаханәсендә баш табиб вазифасын үтәгәндә, Мордовиянең топ дәвалау учреждениесенең матди-техник һәм диагностика базасы ныгый, консультатив поликлиника төзелеп бетә. Тагы ул республикада беренче булып җепсел оптикалы (оптиковолоконный) Япон фирмасының фиброгастродуоденоскоп (ФГДС)ны, гамәлдәге хирург буларак, үзләштерә һәм практикага кертә; башкаларны да кулланырга өйрәтә. Шул һәм башка күп төрле тырыш хезмәте, белеме белән язма героебыз Мордовия медицинасында тирән эз калдыра.
Рафаиль Аширов өч чакырылыш Госсобрание депутаты иде, шул исәптән вице-спикер вазифасында да үз һөнәри тәҗрибәсен гражданнарның иминлеге бәйле булган мәсьәләләрне хәл итү өчен кулланды, дигән идек. Чынлап та, Дәүләт Җыены рәисе урынбасары төрле социаль статустагы кешеләр белән уртак тел таба белде, ул үзен прогрессив фикерләүче, принципиаль сәяси позиция кешесе итеп күрсәтте. Рафаиль Зәки улына милләтара мөнәсәбәтләр проблемалары бик якын, аларның кураторлыгы аның бурычлары даирәсенә керде. Шәһәр, авыл халкы белән очрашулар вакытында ул Мордовиядә милли мәсьәләләрнең беркайчан да кискен тормавын һәм республикабызда төрле халыкларның үзара аңлашуы, толерантлык үрнәге булуын һәрвакыт ассызыклады. Безнең төбәктә 90 милләт вәкилләре яшәвен исәпкә алсак, бу бик кыйммәт тора.
Интернациональ менталитетта Рафаиль Аширов туган татар халкының гореф-гадәтләренә, мәдәниятенә һәм диненә тирән хөрмәт белән карый. Ул аның

тарихы, ин яхшы вәкилләре белән горурлана. Үзе, cvз унаеннан, 1618 елда патша указы белән кенәз титулы бирелгән Мангушев морза нәселеннән.
Биографик мәгълуматка кvз салыйк. Рафаиль Аширов 1946 елнын 15 июнендә хәзерге Ромоданово районы Белозерье авылында туган, ул вакытта әнисе туган татар телен һәм татар әдәбиятын укыткан. Уллары туганнан сон, гаилә Дубенка районынын Ломаты авылында топләнә, әти-әнисе шунда туган. Ә 1949 елда алар Кострома олкәсенен Галич шәһәренә кvченергә карар кылалар. Анда инде дvрт уллары туа, алар мәктәпне тәмамлыйлар, аннары институтларга укырга керәләр. Зәки улы Рафаиль Ярославль медицина институтына укый, аннары хәрби врач булып Армия сафларында хезмәт итә. Шул вакытта ул Ломат авылынын сойкемле якташы Ная Зәки кызы Айзатулловага ойләнә. Ная Зәки кызы гаиләдә союче хатын, кадерле Ана (Ренатлары туа) була. Аннары Саранск шәһәренә кvчеп китәләр. Ленинград химия-фармацевтика институтында провизор белгечлеген алган Ная Зәки кызы Аширова шәһәрнен беренче номерлы хастаханә аптекасын житәкли. Ә Рафаиль Зәки улынын, талантлы һәм эшкә сәләтле белгечнен карьерасы туган иләндә баш әйләндергеч булды. Алты елга якын республика хастаханәсендә эшләде һәм 30 яшендә «Светотехника» (хәзерге «Лисма») житештерv берләшмәсенен медицина-санитария бvлеген житәкләде - Россиядә генә тvгел, Европада да тармакнын ин эре предприятиесе.
Биографиясенен тагы бер мизгелен искә аласы килә. Рафаиль Зәки улы Аshировнын озын профессиональ чоры 2 нче бала тудыру йортын тозv һәм vстерv белән бәйле, ул бvген республикада гына тvгел, илдә дә ин яхшыларнын берсе булып тора. Аннары ул 4 нче номерлы Саранск клиник хастаханәсен житәкли, анда энтузиазм белән сәламәтлек саклау системасын реформалаштыру буенча пилот проектларын тормышка ашыра. Нәкъ менә шул вакытта поликлиникаларны стационарлар белән берләштерә, компьютерлар урнаштыра, медицина учреждениеләрендә хужалык хисабын кертә башлаганнар. Житәкче-новатор оператив рәвештә ботен алдынгылыкны, прогрессивлыкны коралга алган. Шул ук вакытта ул социаль олкәне актив vстерә, хезмәткәрләр очен торак този, унайлырак эш шартлары тудыра. Кыскасы, узган еллар дәверендә анын житәкчелегендә 50дән артык медицина объекты тозелә, алар заманча жиһазландырыла. Һәм атаклы якташыбызнын, пенсиягә чыгу сәбәпле, язмышында борылыш була: ул республиканын Дәвләт жыелышына эшкә кvчә. Ә тагын ярты елдан сон Мордовия татарларынын «Якташлар» тобәк милли-мәдәни автономия житәкчесе һәм Аксакаллар советы рәисе итеп сайлана. Яна вәкаләтләр - остәмә бурычлар һәм йокләмәләр; аларны да унышлы тормышка ашыра. Бvген лаеклы ялда булуына карамастан, Рафаиль Зәки улы Аширов ботен жаваплылыкны анлый һәм респуб-лика житәкчелегенен, якташларынын ышанычын акларга тырыша. Анын тормышы һәм гамәлләре жәмәгатьчелек игътибары vзәгендә.
Рафаиль Зәки улы Аширов менә шундый зур һәм саллы олеш кертә Мордовия автономиясенен 95 еллыгына, Россия дәвләте язмышындагы Мордовия тарихына.

**Наилә НАСЫРОВА**